**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 7** **20.11.2024**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Урсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында 2025 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2025 елда Урсай авыл җирлеге Мослим авылы территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум, 2 төркем инвалидлар өчен, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп, 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Урсай авылында авария хәлләрен бетерү, торбаларын алыштыру,килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җайланмалар сатып алу);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мөслим авылында гравий түшәмәсе урнаштыру);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Мөслим авылы юлларын кардан чистарту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт;
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урсай авыл җирлеге Башлыгы З.Х.Рахимьянова